**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

**27.06.2018** — **№ 1388**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү тәртибен расларга. (Кушымтада бирелә.)

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 04 декабрендәге 1999 номерлы;
- «Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссиянең яңа составын раслау турында» 2016 елның 20 июнендәге 1066 номерлы;
- «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссиянең яңа составын раслау турында» 2016 елның 20 июнендәге 1066 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 09 гыйнварындагы 3 номерлы;
- «Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 04 декабрендәге 1999 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 16 гыйнварындагы 54 номерлы;
- от 25.08.2017 №2105 «ТР Биектау муниципаль районы Башкарма

комитетының «Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссиянең яңа составын раслау турында» 2016 елның 20 июнендәге 1066 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 25 августындагы 2105 номерлы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта

«Расланды»
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 27 июнендәге
1388 номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү тәртибе**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерүнең әлеге Тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 10 августындагы 502 номерлы «Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә формасын раслау хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы «Урынны торак урын, торак урынны итеп яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү эшләрен оештыруны билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү турында, аларның милек формаларына бәйсез рәвештә, карар кабул итүгә гомуми таләпләрне билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерүне (күчерүдән баш тартуны) кабул итү, әзерләү һәм рәсмиләштерү Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге (алга таба - Бүлек) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү мөмкинлеге йә мөмкин булмавы турындагы карар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урынны торак

булмаган урынга һәм торак булмаган бинага күчерү буенча ведомствоара комиссиясе карары (алга таба - МВК) нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районындагы торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү буенча ведомствоара комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә һәм Бүлек тарафыннан урынның функциональ билгеләнешен күчерү (күчерүдән баш тарту) турында тиешле хәбәрнамә бирү өчен нигез булып тора.

1.4. МВК – төзелүе, эш тәртибе һәм составы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана торган коллегиаль орган, даими нигездә эшли һәм үз эшендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Тәртипкә таяна.

## 2. Торак урыннарны торак булмаган урыннарга һәм торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү шартлары

2.1. Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген җайга сала торган Россия Федерациясе законнарын үтәүне исәпкә алып рөхсәт ителә.

2.2. Торак урыннарны торак булмаган урыннарга күчерү шартлары булып тора:

2.2.1. Күчерелә торган урынның торак йортның беренче катында яисә торак йортның беренче катыннан югарырак урнашуы, ләкин шул ук вакытта турыдан-туры күчерелә торган урын астында урнашкан урыннар торак булып тормый;

2.2.2. Күчерелүче урынның аерым изоляцияләнгән керү урыны булу яисә аны җиһазлау өчен техник мөмкинлекләре булу;

2.2.3. Күчерелүче урын торак урынның бер өлеше булып тормый;

2.2.4. Күчерелә торган урын әлеге урын хуҗасы тарафыннан яки башка граждан тарафыннан даими яшәү урыны буларак файдаланылмый;

2.2.5. Торак булмаган урынга күчерелергә тиешле торак урынның барлык милекчеләренең ризалыгы булу;

2.2.6. Нинди дә булса башка затларның хокуклары белән күчерелүче урынга милек хокукы чикләнүе булмау;

2.2.7. Торак урынны торак булмаган урынга күчерү дини эшчәнлекне тормышка ашыру максаты булып тормый;

2.2.8. Күчерелүче торак урын социаль файдаланудагы наемлы йортта тормый.

2.3. Торак булмаган урыннарны торак урыннарга күчерү шартлары булып тора:

2.3.1. Күчерелә торган урынның торак урыннарына куела торган санитар-гигиена, янгынга каршы һәм эксплуатацион таләпләргә туры килүе яисә мондый урынның торак урыннары өчен законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен тәэмин итү мөмкинлеге;

2.3.2. Күчерелә торган урынга милек хокукы нинди дә булса башка затларның хокуклары белән чикләнми.

## 3. Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны

**торак урынга күчерү тәртибе**

3.1. Торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү өчен тиешле бинаның милекчесе (алга таба -Гариза бирүче) яисә ул вәкаләт биргән зат (алга таба - мөрәҗәгать итүче вәкиле) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына яисә тиешле административ регламентта билгеләнгән тәртиптә күпфункцияле үзәккә түбәндәге документларны тапшыра:

3.1.1. Урынны күчерү турында гариза;

3.1.2. Күчерелә торган урынга хокук билгели торган документлар (төп нөсхәләр яисә нотариаль тәртиптә расланган күчермәләр);

3.1.3. Күчерелә торган урынның аның техник тасвирламасы белән планы (әгәр күчерелә торган урын торак булса, мондый урынның техник паспорты);

3.1.4. Күчерелә торган урын урнашкан йортның катлары планы;

3.1.5. Күчерелә торган урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру буенча билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән проект (үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру мондый урынны торак яисә торак булмаган урын сыйфатында файдалануны тәэмин итү өчен таләп ителгән очракта).

3.2. Мөрәҗәгать итүче әлеге Тәртипнең 3.1.3 һәм 3.1.4 пунктларында каралган документларны, шулай ук күчерелә торган урынга хокук Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлгән очракта, 3.1.2 пунктында каралган документларны тапшырмаска хокуклы.

Торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү турындагы гаризаны карау өчен Бүлек мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы белән тәкъдим ителмәгән булса, түбәндәге документларны соратып ала:

1) күчерелә торган урынга хокук Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлгән булса, күчерелә торган урынга хокук билгели торган документлар;

2) күчерелә торган урынның аның техник тасвирламасы белән планы (әгәр күчерелә торган урын торак булса, мондый урынның техник паспорты);

3) күчерелә торган урын урнашкан йортның катлары планы.

3.3. Әгәр күчерелә торган урын ике һәм аннан да күбрәк зат милкендә булса һәм милекчеләрнең яисә башка затларның берсе дә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аларның мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле булмаса, Әлеге Тәртипнең 3.1.1 пунктчасында күрсәтелгән гариза күчерелә торган урынның барлык милекчеләре тарафыннан имзалана.

3.4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, әлеге Тәртипнең 3.1.1 - 3.1.5. пунктлары белән билгеләнгән документлардан тыш, башка документларны да бирүне таләп итәргә хокуклы түгел.

Мөрәҗәгать итүчегә гариза бирүчедән документлар алу турында, аларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

3.5. МВК, тапшырылган документларны карап, аларны Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Тәртип таләпләренә туры килү-килмәүгә тикшерә. МВК эше нәтиҗәләре буенча торак урынны торак булмаган урынга яисә торак булмаган урынны торак урынга күчерү яки күчерүдән баш тарту

турында карар кабул ителә.

Күчерелә торган урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру кирәк булган очракта, мондый урынны торак яисә торак булмаган урын сыйфатында файдалануны тәэмин итү өчен башка эшләр башкарылган очракта, МВК карары аларны үткәрү турында таләп, әгәр аларны үткәрү кирәк булса, башка эшләр исемлеген үз эченә алырга тиеш.

3.6. Күчерелә торган урынны әлеге Тәртипне 3.7 пунктында күрсәтелгән торак яки торак булмаган урын буларак файдалануны тәэмин итү өчен үзгәртеп төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру һәм (яки) башка эшләр заруриылыгы булганда, документта аларны үткәрү турында таләп, аларны үткәрү кирәк булса, башка эшләр исемлеге булырга тиеш.

3.7. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырылуы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар кергән көннән алып 30 (утыз) көннән дә соңга калмыйча, урынны күчерү яисә күчерүдән баш тарту турында карар МВК тарафыннан кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

3.8. Әлеге Тәртипнең 3.6 пунктында күрсәтелгән карарларның берсен кабул итүдән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мөрәҗәгать итүчегә урынны күчерү яисә күчерүдән баш тарту турында карарны тапшыра яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча хәбәрнамә җибәрә.

Мөрәҗәгать итүчегә бирү яисә хәбәр җибәрү белән бергә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты әлеге карарны кабул иткән урынга тоташкан урыннар милекчеләренә күрсәтелгән карарның кабул ителүе турында хәбәр итә.

3.9. Әгәр урынны торак яисә торак булмаган урын буларак файдалану өчен аны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру, һәм (яисә) башка эшләр башкару таләп ителсә, әлеге Тәртипнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документ, әлеге Тәртипнең 3.7 пунктында каралган күрсәтелгән әлеге Тәртипнең 3.1.5 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим ителгән үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру проектын исәпкә алып, һәм (яисә) эшләр исемлеген исәпкә алып, тиешле үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру уздыру нигезе булып тора.

3.10. Тәртипнең 3.9 пунктында күрсәтелгән үзгәртеп кору (яңадан планлаштыру) һәм (яисә) башка эшләрне тәмамлау МВК акты белән раслана. Яңадан кору һәм (яисә) яңадан планлаштыруның төгәлләнүен раслый торган МВК акты Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә җибәрелә. МВК акты урынны күчерү тәмамлануын раслый һәм күчерелгән урынны торак яки торак булмаган урын сыйфатында куллануның нигезе булып тора.

3.11. Урынны торак яисә торак булмаган урын буларак күчергәннән соң файдаланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләре, санитария-гигиена, экология һәм законнарда билгеләнгән башка таләпләр, шул исәптән торак күпфатирлы йортларда торак булмаган урыннарны файдалануга карата таләпләр үтәлергә тиеш.

## 4. Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерүдән баш тарту

4.1. Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерүдән баш тарту түбәндәге очракта рөхсәт ителә:

4.1.1. Әлеге Тәртипнең 3.1.1. - 3.1.5. пунктларында билгеләнгән, аларны тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документларны тапшырмау;

4.1.2. Әгәр тиешле документны мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән бирмәгән булса, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органына ведомство буйсынуынлагы оешманың ведомствоара соратуга торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү өчен кирәкле булган документның һәм (яисә) мәгълүматныңбулмавын таныклаучы җавабы керүе. Күрсәтелгән нигез буенча урынны күчерүдән баш тарту, әгәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты күрсәтелгән җавапны алганнан соң мөрәҗәгать итүчегә мондый җавапны алу турында хәбәр иткән очракта, мөрәҗәгать итүчегәторак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү өчен кирәкле булган документны тапшырырга тәкъдим иткән һәм мөрәҗәгать итүчедән мондый документ һәм (яисә) мәгълүматны белдерү җибәрелгән көннән алып унбиш эш көне эчендә алмаган очракта рөхсәт ителә;

4.1.3. Документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4.1.4. Әлеге Тәртипнең 2 бүлегендә каралган урыннарны күчерү шартларын үтәмәү;

4.1.5. Торак урынын үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру проектының закон таләпләренә туры килмәве.

4.2. Урынны күчерүдән баш тарту турындагы карарны әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында каралган хокук бозуларга мәҗбүри сылтама белән баш тарту нигезләре булырга тиеш.

4.3. Урынны күчерүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә мондый карар кабул ителгән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла яисә җибәрелә һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Тәртипкә
1 нче кушымта

Башкарма комитет җитәкчесенә
кемнән ___________
Почта адресы _____
Элемтә телефоны:__
Электрон почта адресы

**ГАРИЗА**

Түбәндәге зат милкендәге урынга карата «Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү», муниипаль хезмәтен күрсәтүегезне сорыйм

_____________________________________________________________________________

(физик затлар өчен: ФИА, шәхесне раслаучы документ: документ төре сериясе ________, номеры ______________ , кем, кайчан биргән _________ _______________

_____________________________________________________________________________

юридик затлар өчен: юридик затның тулы исеме

___________________________________________________________ __, юридик затның бердәм башкарма органы вазыйфаларын башкаручы затның ФИА

______________________________________________________________________

юридик адресы, ОГРН, ИНН ____________________________________________ ),

урнашкан адресы: Татарстан Республикасы, ___ __

(авыл, урам,)

___________________________________________ _______________________________

(йорт, корылма №)

____________________________________________________________________________

(фатир, урын №) (урынның гамәлдәге билгеләнеше)(торак/торак булмаган)(гомуми мәйдан,торак мәйдан)

(торак/торак булмаган) урыннан (торак булмаганга/торакка)

(кирәклесен ассызыкларга)

Һәм гамәлгә ашырырга __________________________________________________

(үзгәртеп кору һәм (яисә)яңадан планлаштыру)

Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең күчерелгән урынга аерым керү җиһазлау өчен кирәкле гомуми мөлкәтнең бер өлешен файдалануга тапшыруга һәм/яки күчерелгән урынга үзгәртеп корганда һәм (яисә) яңадан планлаштырганда гомуми мөлкәтнең бер өлешен тоташтыруга ризалыгы РФ ТК билгеләгән тәртиптә алынды.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең ахыргы нәтиҗәсен түбәндә күрсәтелгәнчә сорыйм:

КФҮтә шәхсән тапшырырга_________________________________________ ,

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып, электрон документ рәвешендә тапшырырга,

(кирәклесен ассызыкларга)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуны түбәндә күрсәтелгәнчә сорыйм:

КФҮтә шәхсән тапшырырга________________
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып, электрон документ рәвешендә тапшырырга, фактта яшәү урыны (урнашкан урыны) буенча почта аша җибәрергә.

(кирәклесен ассызыкларга)

Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында түбәндә күрсәтелгәнчә сорыйм:
КФҮтә шәхсән тапшырырга________________
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып, электрон документ рәвешендә тапшырырга,

(кирәклесен ассызыкларга)

Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында түбәндә күрсәтелгәнчә сорыйм:
КФҮтә шәхсән тапшырырга________________
Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып, электрон документ рәвешендә тапшырырга,

Мәскәү өлкәсенең «шәхси кабинет» дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы өстәмә системасына теләсә нинди мәгълүмат керүе, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүне яңарту турында миңа хәбәр итүегезне сорыйм _______ ____________________________________________________________ ______________ _____

(мәгълүмат бирүнең формасы һәм ысулы, шул исәптән электрон почта адресы, смс-хәбәр өчен

________________________________________________________________________

телефон номеры күрсәтелә, телефон буенча хәбәр итү өчен телефон номеры)

________________________________________________________________________

(тиешле белешмәләр алу теләге булганда күрсәтелә)

Имза ____________________________________________________

Дата ______________________________

Тәртипкә
1 нче кушымта

РАСЛАНДЫ
Россия Федерациясе
Хөкүмәтенең 2005 елның
10 августындагы 502 номерлы
карары белән

**Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә**
**ФОРМАСЫ**

Кемгә ______________________________
(фамилияме, исеме, атасының исеме –
______________________________
гражданнар өчен;
______________________________
оешманың тулы исеме–
______________________________
юридик затлар өчен)

Кая ______________________________
(гариза бирүченең күчерү турында
______________________________
гаризасы нигезендә почта индексы
______________________________
һәм адресы)
______________________________

**Торак (торак булмаган) урынны торак булмаган (торак) урынга күчерү (күчерүдән баш тарту) турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

______________________________________________________________
(урынны күчерүне гамәлгә ашыручы
______________________________________________________________,
җирле үзидарә органы исеме)

Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясындагы 2 өлеше нигезендә тапшырылган урынны күчерү турындагы документларны карап, гомуми мәйданы __________________ кв. м, түбәндәге адрес буенча урнашкан:

______________________________________________________________
(шәһәр яки авыл җирлеге атамасы)
______________________________________________________________
(урам, мәйдан, проспект, бульвар, юл һәм б.ш. атамасы)

йорт _____, корпус (биләмә, корылма) , кв. _____, торактан (торак булмаганнан) торак булмаганга(торакка)
(кирәкмәгәнен сызарга) (кирәкмәгәнен сызарга)

урынны күрсәтелгән сыйфатта куллану максатында ______________________________
______________________________________________________________
(күчерү турындагы гариза нигезендә,
урыннан файдалану төре)

КАРАР
ИТТЕ ( ______________________________________________________________ ):
(акт исеме, аны кабул итү датасы һәм номеры)

1. Гаризага кушымта итеп бирелгән документлар нигезендә урынны:

а) күчерергә торактан (торак булмаганнан) торак булмаганга (торакка) алдан шартлар куймыйча;
(кирәкмәгәнен сызарга)

б) билгеләнгән тәртиптә түбәндәге эшләрне башкару шарты белән торактан (торак булмаганнан) торак булмаганга (торакка) күчерергә:

_______________________________________________________________________________

(урынны үзгәртеп кору,

_______________________________________________________________________________

(яңадан планлаштыру) буенча яки урынны ремонтлау, реконструкцияләү,

_______________________________________________________________________________

реставрацияләү буенча башка кирәклеэшләр исемлеге)

_______________________________________________________________________________.

2. Түбәндәгеләр нигезендә күрсәтелгән урынны торактан (торак булмаганнан) торак булмаганга (торакка) күчерүдән баш тартырга ____________________________________________

(Россия Федерациясе Торак кодексының 24 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нигез(ләр))

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

| ______________________________ | _______________ | ________________________ |
|---|---|---|
| (хәбәрнамәне имзалаган затның вазыйфасы) | (имза) | (тулы имза) |

“____” _________________ 200__ ел

М.У.